# ТАТАР МУЗЫКАСЫ СӘНГАТЕНДӘ Г. ТУКАЙ МИРАСЫ

ЭЛЬМИРА МӨНИР КЫЗЫ ГАЛИМОВА

İKSAD
Publishing House

Copyright © 2020 by iksad publishing house
All rights reserved. No part of this publication
may be reproduced, distributed,
or transmitted in any form or by
any means, including photocopying, recording, or
other electronic or mechanical methods, without
the prior written permission of the publisher,
except in the case of
brief quotations embodied in critical reviews and
certain other noncommercial uses permitted by
copyright law.
Institution Of Economic
Development And Social Researches
Publications®
(The Licence Number of Publicator: 2014/31220)
TURKEY TR: +90 342 606 06 75
USA: +1 631 685 0 853
E mail: iksadyayinevi@gmail.com
www.iksad.net
www.iksad.org.tr www.iksadkongre.org
It is responsibility of the author to abide by the
publishing ethics rules.
Iksad Publications – 2020©
ISBN:
January / 2020
Ankara / Turkey

**Аннотация**

Творчество Габдуллы Тукая является источником вдохновения для многих известных татарских композиторов. Творческое наследие выдающегося поэта формирует мышление и молодых представителей татарской композиторской школы. Данная статья посвящена теоретическому осмыслению основных музыкальных произведений, которые представлены в энциклопедии Габдуллы Тукая и непостредственно связаны с именем и творчеством великого поэта.

**Ключевые слова:** Музыкальное искусство, музыкальное наследие, композитор, музыкальные жанры, поэзия и музыка.

## Кереш

Г. Тукай шәхесе турында бар нәрсә дә мәгълүм, аның иҗаты һәм үз заманының иҗтимагый тормышында тоткан урыны бар яктан да өйрәнелеп беткән кебек. Ләкин бу беренче карашка гына шулай тоела. Чынлыкта исә, Тукай темасына кагылышлы, өйрәнелмәгән аспектлар чиксез, ул һәр яңа буын тикшеренүчеләренә яңа яктан ачыла, чөнки вакыт

кысалары, тарих вакыйгалары үз кануннарына буйсындыра һәм шул уңайдан фәнни яктан өйрәнер өчен кызыклы юнәлешләр барлыкка килә.

## Татар музыкасы сәнгатендә Г. Тукай мирасы

Г. Тукай энциклопедиясе – бөек шагыйрьгә бәйле булган, бүгенге көндә эле һаман да ачыкланмаган сорауларга җавап табар өчен менә дигән беренче фәнни басма. Энциклопедия – музыка сәнгатенең барлык тармакларын үз эченә алган. Шагыйрь сүзләренә язылган халык җырларының феномен ачыклау, төрле жанрдагы музыкаль әсәрләрне анализлау, әлеге шәхескә багышлап язылган музыкаль-сәхнә үрнәкләренең үзенчәлеген билгеләү, театр һәм кино сәнгатендә әһәмияткә ия булган иҗади мисалларны барлау,

яңа буын композиторларының бүгенге заман ысуллары белән язылган әсәрләрен тасвирлау һәм башка темаларга кагылышлы 140 якын мәкалә урын алган.

«Тукай һәм татар музыкасы» бәйләнеше, тема буларак, мәгариф системасында киң чагылыш таба. Шулай ук әлеге мәсәлә фәнни яктан А. Алмазова, Г. Гобәйдуллина, Й. Исәнбәт, Р. Исхакова-Вамба, М. Нигъмәтҗанов, З. Сайдашева, Ф. Салитова, Ф. Арсланова, И. Газиев һәм башка музыка белгечләре хезмәтләрендә тикшерелде.

Әйтергә кирәк, Г. Тукай иҗаты - татар музыкасының формалашуына һәм алга таба үсеш

алуына зур этәргеч бирде. Ни өчен дигәндә, иң беренче мәсәлә итеп, музыка белгечләре фольклор үрнәкләрен күздә тотып, шагыйрь иҗаты белән халык көйләренең бәйләнешен өйрәнәләр. Әлбәттә, бу юкка түгел, чөнки Тукай көчле тавыш иясе булмаса да, ул илһамланып Коръән сүрәләрен, «Мөхәммәдия» китабын, борынгы татар бәетләрен, мөнәҗәтләр һәм озын көйләрне җырларга яраткан. Китап уку көйләренең ритмик калыбын ассызыклап, халык җырларының «моң» феноменын билгеләгән үзенчәлекләрне күңеле белән шагыйрь тоя белә. Тукайның «Милли моңнар» шигыре

«Әллүки» көе белән илһамланган, «Өзелгән өмид»нең музыкаль-поэтик символы булып саз, ә «Авыл җырлары» шигырьләр циклының нигезендә халык җырлары тора. Әлеге татар музыкасының нигезендә яткан халык җырлары турында энциклопедия битләреннән тирәнтен мәгълүмат алып була.

Энциклопедиянең музыка сәнгатенә һәм музыкаль фольклор юнәлешенә кагылышлы өлешен барлап чыккач, берничә фикер белән уртаклашасы килә. Фәнни басма алфавит буенча эзлекле юнәлеш белән төзелгән һәм шул яклап эшләнүе дә кулланучылар

өчен уңайлы икәнен исбатлый. Гомүмән алганда, татар музыкасы сәнгатендә Г. Тукай мирасын өч юнәлешкә бүлеп, фәнни яктан өйрәнеп була. Әлеге фикер энциклопедия эчтәлегендә дә чагылыш таба.

Беренче юнәлешкә югары сәнгать төренә караган Г. Тукай шәхесен күздә тотып язылган һәм бөек шагыйрьнең тормышын чагылдырган әсәрләрне атар идем. Татар музыкантларының композиторлык эшчәнлегендәге беренче иҗади эшләренә бәя бирү һәм тарихи фактлар белән ачыклык кертү энциклопедиянең уңышлы ягын билгели. Шагыйрь мирасы

милли композиторларыбызның С. Сәйдәшев, Ф. Яруллин, Н. Җиһанов, М. Мозаффаров, А. Ключарев, Җ. Фәйзи, З. Хәбибуллин иҗатында төрле жанрлардан гыйбәрәт: вокаль һәм инструменталь миниатюралардан алып, зур күләмле симфоник музыкасы үрнәкләре һәм музыкаль-сәхнә әсәрләренә кадәр.

Тарих битләренә куз салсак, революциягә кадәрге камера инструменталь музыканың башы Тукайның чордашы Заһидулла Яруллин исеме белән бәйле һәм ул аның «Тукай маршы»ннан башлана. Берничә дистә елдан соң, композитор Н.Җиһанов әлеге

әсәрне симфоник оркестры өчен оркестровка эшли.

Композитор М. Мозаффаров «Тукай истәлегенә» дип аталган (1952) симфоник поэмасында шагыйрьнең исеме халык бәхете өчен көрәшүченең символы буларак яңгырый. Әсәрнең беренче музыкаль темасы татар шигърияtенең чәчәк атуын тасвирлаcа, икенчесе Тукайның яраткан «Анам кабере янында», дип исемләнгән татар халык җыры цитата буларак яңгыраш ала.

Тукай мирасын мәңгеләштерү йөзеннән композитор Р.Ахиярова «Моңлы сазым» (1986) симфоник поэмасын иҗат итә. Әсәрнең

үзенчәлеге «Туган тел» көен цитата буларак
куллану. Әлеге тема шагыйрь тормышының лейтмотивы буларак лирик хәләтеннән чыгып, ахырга таба гимн кебек янгырый.
«Туган тел» көе шулай Р. Калимуллин иҗат иткән «Г. Тукай истәлегенә», дип исемләнгән квартет нигезендә яңгырый. Кыска интонацион лейттемадан этәргеч алып, аны эзлекле үстереп (тембр, фактура, метроритм ягыннан), композитор оркестровка ярдәмендә динамик үсештәге композиция тудыра. Симфоник жанрын күздә тотып, композитор Р.Кәлимуллинның. «Тукай

көйләре» (2000) кыллы уен кораллары өчен язылган симфониииясен искә алмыйча булмый. Аның әлеге әсәрләре энциклопедияда теоретик анализлау ягыннан бирелә.

Г. Тукайның 120-еллыгы уңаеннан композитор Р. Ахиярова «Шагыйрь мәхәббәте» операсын Р. Харис либреттосына нигезләнеп иҗат итә. Операның эчтәлеге мәхәббәт фабуласы белән генә чикләнми. Шулай ук шагыйрь тормышының аерым мизгелләрен, аның иҗади казанышларын әсәр аша күрсәтү, авторлар үзенә максат итеп куя. Р.Харис либреттода Тукай тормышыннан

автобиографик фактларны куллана, әсәргә аның шигырьләреннән өзекләрен кертә, аның эчке кичерешләрен (мәхәббәткә омтылуын, үлемнән куркуын) чагылдыра. Энциклопедияда әлеге әсәрнең язылу тарихы турында һәм музыкасына карата төгәл һәм тулы мәгълүмат бирелә.

Яшь композитор буларак, Г. Тукайның 125-еллыгына Р.Батулла пьесасы буенча

«Зәйтүнәкәй», дип исмеләнгән музыкаль драма иҗат иттем. Әсәрне 2011 елда режиссёр Ринат Әюпов Г.Кариев исем. Казан Татар Дәүләт яшь тамашачылар

театрында сәхнәләштерде. Драманың үзәгендә булган Зәйтүнә образы, музыкаль характеристика ягыннан, ике лейтмотив аша бирелә. Шуның берсе «Зәйтүнә җыры» гади, шул ук вакытта нәзәкатьле, бөек шагыйрьгә карата мәңгелек мәхәббәт утында янган гүзәл кыз образы тудыра. Әсәрнең башка үзенчәлекләре турында тулырак мәгълүмәтне энциклопедия битләрендә таба аласыз. Әлеге әсәр өчен язылган «Ак канатлы шагыйрь» гимны, шул ук елны Мәскәүдә бөек шагыйребезгә һәйкәл ачу тантасында яңгырый. Цитата буларак кулланылган “Туган тел”

Һәм “Тәфтиләү” көйләре татар милләтенең якты киләчәген тасвирлый.

Икенче юнәлешкә без Г. Тукайның экиятләренә нигезләнеп язылган музыкаль әсәрләрне кертәбез. Әлбәттә Шүрәле - иң яратылган образларның берсе. Мисал итеп И. Якубовның ораториясен, А. Ключарёвның иҗат иткән фортепиано өчен әсәрләрен әйтеп була. Симфоник жанрлар арасында: Н. Җиһановның «Кырлай» һәм «Шүрәле» симфоник поэмасы, М. Шәмсетдинованың «Тукай экиятләре» сюитасы зур игътибарга лаек.

Балет жанры Г. Тукай экиятләренең үзенчәлеген чагылдыру өчен менә дигән жанр. Әлбәттә, дөньякүләм танылган композитор Ф. Яруллиның “Шүрәле” балеты татар музыка сәнгатенең йөзек кашы булып юкка гына саналмый. Бүгенге көнгә кадәр театр репертуарында әлеге әсәр саклана. Ни өчен дигәндә, композиторның музыка язу үзенчәлеге милли көйләрне заманча ысуллар белән баетудан гыйбәрәт. Композиторның бөеклеген әлеге әсәр дәлилли һәм шул чорының музыкаль ачышы дип, атарга була.

Балет жанрында 1957 елда Ә.

Бакировның «Су анасы», ә 1958 елда Р. Губайдуллин 1958 елда «Кисекбаш» әсәрләре куела. Энциклопедия әлеге әсәрләрнең язылу тарихын
ачыклый. Ләкин ике балетның да иҗади гөмерләре озын булмый. Музыка белгечләре либреттоның артык персонажларга күп һәм музыканың төрле стильдә язылуын сәбәп итеп куя.
2013 елда Г.Кариев исем. Казан Татар Дәүләт яшь тамашачылар театры, Т. Миңнуллин пъесасына нигезләнеп, яңа жанрда балалар өчен «Әйт әле күбәләк» музыкаль мистерия премьерасын күрсәтә. Композитор буларак, минем өчен

бу бик үзенчәлекле эш булды. Режиссёр Р. Аюпов әсәрдә төп рольне музыкага тапшыра һәм актёрларны драматик диалоглардан азат итә. Пластик хәрәкәтләр ярдәмендә балалар төп эчтәлекне аңлыйлар. Г. Тукайның бөтен әкият геройлары белән кечкенә Апуш курку хисен җиңә, ә күбәләк аны киләчәк иҗатында кыю фикерле булырга өнди.

Өченче юнәлешкә без бөек шагыйрь сүзләренә нигезләнеп иҗат ителгән музыка әсәрләрен кертер идек. Г. Тукай шигърияте вокал жанрының үрнәкләрен үстерү өчен һәм кабатланмас җырлар иҗат итәргә композитор

өчен менә дигән илһам чыганагы. Мәсәлән, Солтан Габәшинең 1915-1917 елларда Тукай сүзләренә «Юаныч» һәм «Галәл гомья», «Мәҗрух указ» романслары бик кызыклы, чөнки композитор Тукай шигъриятенең поэтик үлчәмен игътибарга алып үзенчәлекле көйләр яза. Гәбәши
«Бишек җыры»н хор өчен эшкәртүе дә жанр ягыннан яңалык. Шулай ук ул 1925 елда, татар музыкасы тарихында беренчеләрдән булып, «Ике заман» исемле хор циклын иҗат итә.
Шагыйрь иҗаты Н.Җиһанов, Ж.Фәйзи, М.Мозаффаров, З.Хәбибуллин, А.Монасыйпов,

Ф.Әхмәтов, Р.Еникеев, И.Якубов, М.Шәмсетдинова, Р.Ахиярова, Р.Кәлимуллин җыр һәм романс циклларында, халык җырларының эшкәртмәләрендә, балалар өчен язылган әсәрләрендә дә чагылыш таба. Шулай ук Р. Яхинның «Шагыйрь» драматик монологы, «Мәхәббәт җыры» лирик романсы аеруча дан казанган вокаль әсәрләр.

А. Монасыйпов иҗаты тирән мәгънәле әсәрләрдән тора. Аны замандашлары татар музыка сәнгатенең симфонисты дип атыйлар. Зур күләмле әсәрләре арасыннан баритон һәм симфоник

оркестр өчен язылган «Тукай аһәңнәре» вокаль-симфоник поэмасы өчен (1974), композитор шагыйрьнең үз халкына ялкынлы мәхәббәтен, ышанычын һ.б. темаларны эченә алган «Туган җиремә», «Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен...» («Сәрләүхәсез»), «Туган авылым», «Тәүбә вә истигъфар», «Өзелгән өмид», «Белмәдем» («Мөридләр каберстаныннан бер аваз»), «Бу ямьсез болыт» («Татар яшьләре») исемле 7 шигырен сайлап ала. Әсәрнең музыкаль телендә Тукай шигырьләренә язылган («Пар ат», «Туган тел») лирик халык җырлары интонацияләре һәм

Гендельнең пассакалиясеннән алынган үткен цитаталар бергә үрелеп бара.
Энциклопедиянең киң колачлы фәнни басма икәнлеге, игътибар үзәгенә Г. Тукай иҗаты белән бәйле булган музыка сәнгате әһелләренең иҗади эшчәнлеген тасвирлау да күрсәтә. Г. Тукай сүзләренә язылган җырлар, романсларны башкаручы татар халкының милли җырчылары – И.Шакиров, У. Әлмиев, Г.Рәхимкулов, Х.Бигичев, Э.Җәләлетдинов, Ф. Сөләйманова И.Газиев, З.Сәхәбиева һ.б. иҗат юллары белән энциклопедиядан танышып була. Тукай темасына

кагылган төрле жанрдагы әсәрләр республикабызның музыкаль коллективлары репертуарында да урын алган. ТР дәүләт симфоник оркестры, ТР халык уен кораллары Дәүләт оркестры,

«La Primavera» Казан
дәүләт камера оркестры, ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, ТР дәүләт фольклор музыкасы ансамбльләре турында энциклопедияга кергән мәкаләләрдә мәгълүмат туплап була.

## Йомгак

Г. Тукай иҗаты – тулы бер гасыр дәвамында тирәнтен, эзлекле өйрәнелгән иҗат. Бүгенге «Г. Тукай энциклопедиясе» татар милләтенә милли бүләк һәм төрки халыклары өчен тагын бер зур ачыш булуын дәлилли. Әмма, алга таба шагыйрьнең тормышы һәм иҗади мирасында яңа эзләнүләргә һәм ачыш табышларга һәрвакыт җирлек бар. Г. Тукай шәхесенә махсус багышланган энциклопедия алдагы максатларны билгеләргә ярдәм итәр, дип ышанып калам.

**Чыганаклар**

**ТУКАЙ,** Габдулла, (2016), *Энциклопедия. Гл. ред. З.З. Рамеев,* Казань